**Киемнәрегездән агын киегез**

# *Мәчеткә барганда иң яхшы киемнәрегезне киегез*

**Аллаһы Тәгалә “Нур” сүрәсенең 36-37 нче аятьләрендә әйтте:**

**“Аллаһының нуры мәсҗидләрдә булыр“.**

Аллаһы боерды ул мәсҗидләрне зурларга һәм Аллаһы исемен зекер итәргә.

Ул мәсҗидләрдә Аллаһыга тәсбих әйтерләр иртәләрдә вә кичләрдә.

Алыш-биреш итеп сәүдә эшләренә алынмый торган ирләр, аларны алдый алмады дөнья эше Аллаһы зекереннән, вә намазлардан, вә зәкәт бирүдән.

Алар күңелләр вә күзләр тетрәнгән кыямәт көненең катылыгыннан куркалар.

Бу аятьтә Аллаһы Тәгалә мәчетләрнең ни өчен кирәклеген, ни өчен төзелгәнен ачык итеп аңлатып бирә.

**Пәйгамбәребез әйтте:**

**“Кыямәт купмас, хәтта кешеләр мәчетләр белән мактаныша башлаганчы“.**

Мәчетләрнең зурлыгы,
матурлыгы,
байлыгы,
манараларының биеклеге һәм башка шундый әйберләр белән мактанышу бүгенге көндә мөселманнар арасында киң таралган

һәм бу, Пәйгамбәребез әйткәнчә, кыямәт якынлашуның билгесе.

Мондый мактанышулар Аллаһының хак дине булган Ислам диненә каршы килә, чөнки мәчетләр - Аллаһыга гыйбадәт кылу өчен генә билгеләнгән йортлар.

**Пәйгамбәребез әйтте:**

“Мәчетләрегезне сабыйлардан,
диваналардан,
сату-алу эшләреннән,
низаг-талашларыгыздан,
тавышларыгызны күтәрүдән саклагыз“.

**Пәйгамбәребез мәчетләрнең пычрануына китерә торган яки Аллаһыны искә алудан башка тавышларның чыгуына китерә торган сәбәпләрне мәчетләрдән ерак тотарга куша.**

Пәйгамбәребез дә мәчетләрнең ни өчен төзелгәнен аңлатып әйтте:

**“Мәчетләр Аллаһыны зекер итәр өчен һәм намаз укыр өчен генә төзелде“.**

Мәчетләр никах уку
яки исем кушу,
яки мәеткә җеназа уку өчен каралмаган.

Насара динендә булучылар гына бу мәрасимнәрен чиркәүләрендә үтиләр, ә безне Пәйгамбәребез аларга охшаудан тыйды.

**Язид Әл-Кинди сөйләгән:**

«Гомәр ибн Әл-Хаттаб миңа әйтте: «Теге икәүне китер әле». Һәм мин ул әйткән ике кешене китердем.

«Сез кем?» - дип сорады.

Алар әйттеләр:

«Без Таиф шәһәреннән».

Гомәр әйтте: «Әгәр Мәдинә әһелләреннән булсагыз, сезгә җәза бирер идем, Аллаһының илчесе мәчетендә тавышларыгызны күтәрәсез. Кайда икәнегезне беләсезме сез?!»

**Ягъни Гомәр хәлифә булган вакытта тавышланырга ярамый икәнен белеп тә, мәчеттә тавышланган кешегә суктырып җәза бирү каралган булган.**

Мөселман кеше мәчеткә кергәндә үк Пәйгамбәребез өйрәткән догаларны укып керергә тиеш:

«Әй, Аллаһы, миңа рәхмәт ишекләреңне ач», - дип.

Һәм мәчеттән чыкканда да дога укып чыгарга:

«Әй, Аллаһы, миңа фазыйләт ишекләреңне ач», - дип.

Алда китерелгән аятьтәге

«...ул мәчетләрдә Аның исеме зекер ителә...», - дигән сүзләрне Ибн Габбас: «Аллаһының китабы Коръән укыла», - дип аңлатты.

«Әграф» сүрәсенең 204нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

**«Һәм әгәр Коръән укылса,**
**аңа колак салыгыз һәм шым булыгыз, шулай эшләсәгез, бәлки, Аллаһының рәхмәтенә ирешерсез».**

Бу аятьтә Аллаһы Тәгалә намаздагы Коръән уку яки намаздан тыш уку дип, ишетсәң яки ишетмәсәң, дип аермый, ә гомумән әйтә.

Шулай булгач,
мәчеттә Коръән намаз вакытында укылса да,
намаздан тыш укылса да, аны тыңлау һәм шым тору вәҗип була.

Гыйбадәттән башка эшләр белән шөгыльләнү, сөйләшеп утыру, хәтта сөйләшмәсә дә, Коръәнне тыңламыйча утыру - Аллаһы Тәгаләнең әмеренә каршы килү, көферлек. Мәчеттә Коръән укуны бидгать, дип әйтүче йөрәкләре каралган кайбер кешеләр Аллаһының сүзләре булган Коръән укылганда көлешеп, сөйләшеп торудан да тартынмыйлар.

**Кайберләре Коръән укыла башласа, чаба-чаба мәчеттән чыгып китәләр.**

Мәчеттә Коръән уку бидгать булып, ә дөнья сүзләре сөйләшеп, көлешеп тору Коръән-сөннәт булырга мөмкинме?!

Әлбәттә, юк!

Алар тәүбә кылып, кире иман китерсеннәр иде, Аллаһы Тәгалә аларны да туры юлга күндерсә иде.

**«Әграф» сүрәсенең 29нчы аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:**

«Әй, Мөхәммәд, әйт.

Раббым миңа һәр эштә гаделлекне боерды

вә һәр мәсҗидтә йөзләрегезне кыйблага юнәлдерегез,

вә динне Аллаһы ризалыгы өчен генә ихлас тотып,

Аңа гына гыйбадәт кылыгыз».

**Ягъни һәр мәчет - Аллаһының йорты һәм һәр мәчеттә намаз уку тиеш.** Бу мәчеткә бармагыз, теге мәчеткә барыгыз, дип әйтүчеләр алда әйтелгән Аллаһы Тәгаләнең сүзләренә каршы киләләр. Аллаһы Тәгалә тигез кылган әйберне Аллаһыдан өстен булып ничек аерырга мөмкин?!

**«Әграф» сүрәсенең 31нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:**

«Әй, Адәм балалары! Һәр сәҗдә кыла торган урында гаурәтләрегезне каплар өчен зиннәтле киемнәрегезне киегез».

Пәйгамбәребез әйтте:

**«Киемнәрегездән агын киегез, чөнки ул - киемнәрегезнең иң хәерлесе.**

«Әнфәл» сүрәсенең 35нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

**«Мөшрикләрнең Кәгъбә янында үтәгән намаз-гыйбадәт дигәннәре һичнәрсә булмады, мәгәр сызгыру һәм кул чабып тавышлар чыгару гына булды.**

**Төрле тавышлар чыгару, кычкырулар мөшрикләрнең гадәтләреннән, гыйбадәтләреннән. Андый эшләр мәчетләрдә тыела».**

«Тәүбә» сүрәсенең 17-18нче аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

«Көферләргә кәгъбәне төзәтүләрендә аларга савап булмас, үзләренең кәфер икәнлеге белән шаһитлык биреп торган хәлләрендә, аларның бөтен эшләре вә гамәлләре батыл, һичберсенә савап юк, алар җәһәннәмдә мәңге калачаклар.

Ягъни алар үзләре үк үзләренең мөшрик булуларына шаһитлык бирәләр, *«мин - насара»* яки *«мин - яһүди»* яки *«мин - мөшрик»,* дип.

Мәсҗидләр ясап савап алучы, фәкать Аллаһыга вә ахирәт көненә иман хис китергән һәм намазларын вакытында укып, зәкәтләрен биргән, һичкемнән курыкмыйча, Аллаһыдан гына курыккан хак мөэминнәрдер, бу эшләрне эшләгән кешеләрнең һидәяттә булулары өметледер».

Мәчетләрне чын тергезүчеләр булып, аны төзүчеләрдән дә бигрәк бер Аллаһыга гына ихлас күңелдән гыйбадәт кылып, мәчеткә йөрүчеләр тора. Пәйгамбәребез әйтә:

**«Әгәр бер кешенең мәчеткә даими йөрүен күрсәгез, аның иманлы булуына шаһитлык бирегез».**

Мәчеткә намазларга даими йөрү кешенең иманын күрсәтә, иманының билгесе булып тора.

Шулай ук Пәйгамбәребез әйтте:

**«Әгәр Аллаһы Тәгалә бер кавемгә чир җибәрергә теләсә, мәчет әһелләренә карар һәм ул бәлане кире кайтарыр».**

Мәчетләр сәбәпле, күп бәлаләр китә, ягъни Аллаһыга гыйбадәт кылу белән тергезелгән мәчетләр сәбәпле, үле мәчетләр сәбәпле түгел.

Пәйгамбәребез әйтте:

**«Сарыкларның бүресе булган кебек үк, шайтан - кешенең бүресе, бүре аерылган һәм читтә йөргән сарыкларны ала. Берүк, аерылудан сак булыгыз, җәмәгать белән, күпчелек һәм мәчетләр белән бергә булыгыз!»**

Һәм хәзерге заманда да күрәбез: мөселманнар арасында таралган фиркаләр һәм секталар мәчетләрдә түгел, ә мәчетләрдән тыш җирләрдә җыелалар, андый җирләргә барудан сак булыгыз, чөнки Пәйгамбәребез безне бу турыда кисәтте.

**Аллаһы Тәгалә «Җен» сүрәсенең 18нче аятендә әйтте:**

«Һәм мәчетләр Аллаһыга гыйбадәт кылу өчен.

Аллаһы белән бергә һичкемне зекер итмәгез.

Һичкемгә гыйбадәт кылмагыз».

**Сәхабәләр әйтәләр иде**:

«Мәчетләр - Аллаһының җирдәге йортлары. Мәчеткә Үзен зиярәт кылырга килүчене Аллаһы, әлбәттә, хөрмәт кылыр».

Ягъни мәчеткә йөрүчеләргә Аллаһы Тәгалә Үзенең дөнья вә ахирәт нигъмәтләрен бирер.

Кешене иза кылу, рәнҗетү мәчетләрдә бигрәк тә ярамый.

Хәтта башка кешегә намаз укырга комачауларлык итеп пышылдап сөйләшү

яки Коръән уку да ярамый.

Кеше йортына керсәк, ничек үзебезне яхшы тотарга тырышабыз.

Ә галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы йортларына керсәк, без үзебезне ничек тотарга тиеш ?!

Әлбәттә, күпкә әдәплерәк,

тыйнаграк һәм бөек Аллаһы каршында мескен бәндә икәнебезне тоеп.

**Пәйгамбәребез әйтте:**

«**Җир йөзендә Аллаһыга иң сөекле урыннар - мәчетләр, иң сөйкемсез урыннар - базарлар».**

Аллаһы ризалыгына ирешәсебез килсә, Аңа сөекле урында мөмкин кадәр күбрәк булуыбыз тиешле түгелме?!

**Рәфыйк хәзрәт МИҢНЕӘХМӘТ.**

Парлы буласыгыз килсә, “Алеф”ка килегез!



Дөнья мәшәкатьләренә чумып, үз тормышыгызны онытып җибәрмәгез.

Никадәр генә мул тормышта яшәсәгез дә, һөнәр иясе булсагыз да, торак урыныгыз яхшы булса да - бу әле чын бәхет түгел.

Чын бәхет - ул эштән арып кайткач, сөйгәнеңнең елмаеп каршы алуы, кичләрен бергәләп сөйләшеп утыру, төннәрен хисләргә хозурлану.

Ходай Тәгалә барлык тереклекне парлы иткән.

Парлы яшәү - ул кешенең яшәешенә нур өсти, тормыш-көнкүрешен җиңеләйтә, адәмнең гомерен озынайта.

Тулырак мәгълүматны түбәндәге телефон аша белә аласыз:

**8-919=800-01-49.**

“Алеф” фирмасының максаты бер - татар-башкортларны гаиләле итү, бәхетле итү.

## *Изге Болгар*

Идел. Урал. Борынгы Болгар.
Киң елгалар, биек таулар.
Болгар - татар тарихында
Тирән эз калдырганнар.
Үзен татар дип таныган
Һәркем тамырын карар.
Болгар хатирәләргә бай булган,
Ходай аларны динсезлектән коткарган.
Ислам динен кабул иткән
Борынгы Болгарның тарихы.
Болгар өстендә көмеш ай,
Азан моңы иңә нурдай.
Ниятләр зурдан, боерса Ходай,
Йөзләрен кыйбла тарафына юнәлдергән,
Намаз үтәмәккә хатирәләр төзелешкән.
Борынгы Болгар
Ниләр генә күреп бетермәгән.
Утларда янган, суларда баткан,
Явыз дошманнарга каршы торган,
Мөселман булуын ул ташламаган.
Болгар иле, төньяк үзәгенә
Мөселманлык килгән икән изгелектән.
Рухыбызга, күңелебезгә нурын салганы,
Тарихыбызга, милләтебезгә юлын сызган.

**Зиннур КӘРИМОВ.**

## Тик Ислам гына коткарыр

**Җәлил хәзрәт Фазлыев:**

“Әле җир йөзендә Исламнан башка бер генә диннең дә кешелек дөньясын хәмер эчү,

отыш уеннары уйнау,

яман күренешләрдән азат итә алганы юк.

Чын Ислам кануннары буенча яшәгән илләрдә әлеге афәтләр юк”.

* * *